# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

« 15 » 06 2026 ел Яр Чаллы № 1958

2027 финанс елына һәм 2028 - 2029 елларга
Тукай муниципаль районы карары проектын
әзерләү һәм карау графигын раслау турында

Тукай муниципаль районы уставының 92 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет Кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2026 елның 8 маендагы 1496 номерлы карары белән расланган «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү тәртибенә» таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына Тукай муниципаль районының бюджет проектын төзегәндә әзерләнә торган карарлар, документлар һәм материаллар проектын әзерләү һәм карау графигын расларга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Н. Әмирхановага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

ТМР Башкарма комитетының 2026 елның
___ ________ ___ номерлы карарына
кушымта

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН

Тукай муниципаль районы ФБП рәисе

____________________ Әмирханова Р.Н.

**2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына Тукай муниципаль районының бюджет проектын төзегәндә әзерләнә торган карарлар, документлар һәм материаллар проектын әзерләү һәм карау графигы**

| № | Материаллар һәм документлар | *Җаваплы башкаручы* | Тапшыру срогы | Кая бирелә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Эшчәнлекнең төп төрләрен учреждение уставы (бүлекчә нигезләмәсе) нигезендә төгәлләштерү | *Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, мәдәният бүлеге, «Мәгариф идарәсе» МКУ, ТМР Башкарма комитеты* | 1 апрельгә кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге |
| 2. | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль биремдә учреждениегә билгеләнгән муниципаль хезмәтләр (эшләр) исемлеген төгәлләштерү | *Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, мәдәният бүлеге, «Мәгариф идарәсе» МКУ, ТМР Башкарма комитеты* | 1 апрельгә кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Учреждение (бүлекчә) эшчәнлеген үстерү һәм оптимальләштерү чаралары исемлеген төгәлләштерү | *Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, мәдәният бүлеге, «Мәгариф идарәсе» МКУ, ТМР Башкарма комитеты* | 1 апрельгә кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге |
| 4. | Коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләр исемлеген төгәлләштерү | *Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, мәдәният бүлеге, «Мәгариф идарәсе» МКУ, ТМР Башкарма комитеты* | 1 апрельгә кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге |
| 5. | ТМР бюджеты бүлүчеләренең чыгым йөкләмәләре реестрлары | *ТМР ФБП* | 16 апрельгә кадәр | Финанс министрлыгы |
| 6. | Район бюджетының муниципаль программаларын алга таба гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр | *Муниципаль программаларны җаваплы башкаручылар* | 15 майга кадәр | Финанс-бюджет палатасы |
| 7. | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелгән, 2026 елның 1 гыйнварена муниципаль берәмлек милкендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юллары (шул исәптән каты өслекле) исемлеге | *Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге, авыл җирлекләре* | 15 майга кадәр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13. | Тукай муниципаль районы бюджеты турында карар проектына материаллар, шул исәптән: | *ТМР ФБП* | 15 ноябрьгә кадәр | ТМР Башкарма комитеты |
| | - «2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты турында» карар проекты | | | |
| | - 2027-2029 елларга бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре | | | |
| | - 2025 елның узган чоры өчен ТМР социаль-икътисадый үсешенең якынча йомгаклары һәм 2026 елда ТМР социаль-икътисадый үсешенең көтелгән йомгаклары | | | |
| | - 2027-2029 елларга ТМР социаль-икътисадый үсеш фаразы | | | |
| | - 2027-2029 елларга Тукай муниципаль районының берләштерелгән бюджеты төп характеристикалары фаразы | | | |
| | - муниципаль программаларның паспортлары (паспорт проектлары) | | | |
| | - 2026 елга бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү | | | |
| | - «2027 елга, 2028 һәм 2029 еллар план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты турында» карар проектына аңлатма язуы | | | |
| | - бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәп-хисаплары | | | |
| | - 2027-2029 елларга бюджетлар керемнәрен һәм бюджетлар дефицитын финанслау чыганакларын классификацияләү статьялары буенча исәп-хисаплар | | | |